# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегең Сәрдекбаш авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

26 ноябрь 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Сәрдекбаш авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Сәрдекбаш авылын территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (юлларга вак таш һәм асфальт салу, карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (Сәрдекбаш авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (Сәрдекбаш торак пунктында агачларны кисү, ял итү зоналарын булдыру, төзекләндерү һәм карап тоту, спорт һәм балалар уен мәйданчыклары һәм инвентарьлар сатып алу; проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, хоккей мәйданчыгын ремонтлау һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **традицион күмү урыннарын ремонтлау, койма тоту, төзекләндерү**;(Сәрдекбаш авылы зираты территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, койма тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

(Сәрдекбаш авылы зиратында агачларны кисү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, зиратны төзекләндерү буенча башка эш төрләре);
- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;
- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Сәрдекбаш авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);
- **тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре); проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, урам электр челтәрен төзү, карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (Сәрдекбаш авылында янгын гидрантларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, янгын инвентаре сатып алу, ДЕПОны ремонтлау, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган машина сатып алу һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасын тотуга чыгымнар; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

3. Әлеге карарны Сәрдекбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сәрдекбаш авыл җирлеге
башлыгы: Нәбиев И.М.

ОГРН 1021607752858
ИНН 1623001854